Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү буенча

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

10 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак Чишмә торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенеә керүче Ак-Чишмә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр бәлигъ булган кешедән 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Ак Чишмә торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм грейдерлау (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- Ак Чишмә торак пунктында су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

-Ак Чишмә торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урамнарны яктыртуның энергияне саклый торган лампаларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ремонтлау.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М.Н.Мусин